# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«12» февраль, 2026

№ 3

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Нырья авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2025 елның 26 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Нырья авылы торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Нырья авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2025 елның 26 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласындагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Карардагы «торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нырья авылының Комсомол урамында юлларны рәтләү, ремонтлау һәм вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, дренаж системасы ясау, суүткәргеч торбалар сузу, эш өчен шартнамә буенча түләү, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре)» сүзләрен «торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. Карардагы «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап

□

тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Нырья авылында су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре)» сүзләрен «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. Карардагы «торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт һәм уен мәйданчыклары, халыкның башка күпләп ял итү урыннарын, авыл клубын, аның янындагы территория) карап тоту, төзү, ремонтлау, Нырья дигән язу сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү, Нырья авылы территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре)» сүзләрен «торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. Карардагы «янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантлары өчен будканы тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Нырья авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре)» сүзләрен «янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга.

1.6. Карардагы «тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, яктырткычлар һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)» сүзләрен «тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

Нырья авыл җирлеге башлыгы
урынбасары вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы: Р.П. Павлов

ОГРН 1021607753111
ИНН 1623002336